РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 декабрь, 2024 ел Кукмара ш. № 285

Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 91 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара районы прокурорының 2024 елның 14 декабрендәге Прдп-10-24 номерлы протестын карап, Кукмара муниципаль районы Советы **карар кабул итте**:

1. Кумара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 91 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (2021 елның 17 декабрендәге 97 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 197 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 225 номерлы, 2024 елның 29 мартындагы 243 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 12 пунктчаны өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларын имин эксплуатацияләүгә һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә карата таләпләр, шулай ук күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә караган вентиляция һәм төтен чыгу каналларын тоту таләпләре»;

1.6. пунктның 1 нче пунктчасында «1 – 11» саннарын «1 – 12» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район башлыгы С.Д. Димитриев